СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

2023 елның «7» сентябрь Алабуга шәһәре № 279

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2013 елның 7 февралендәге 290 номерлы «Коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне, чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән өчен җәзаларны куллану һәм бурычларны үтәмәү турында»карарына үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2023 елның 13 июнендәге 258-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Алабуга шәһәр Прокурорының кисәтүен карап, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2013 елның 07 февралендә кабул ителгән 290нчы номерлы карары белән расланган чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турында таләпләрне үтәмәгән өчен җәзаларны куллану тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2.5 пунктының 2 абзацын түбәндәге эчтәлектәге сүзләр белән тулыландырырга:

яки 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13.4 статьясына ярашлы рәвештә коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе Президенты хакимиятенең вәкаләтле бүлекчәсе тарафыннан;.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Муниципаль төзелеш һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Рәис Р. М. Нуриев